СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ**
**08 сентябрь, 2025 ел**

**КАРАР**
**№ 548**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Айбаш, Алан-Бәксәр, Әлдермеш, Каенлык, Бөреле, Олы Битаман, Олы Кавал, Биектау, Дачный, Дөбъяз, Иске Казан, Казаклар, Красносельский, Коркачык, Мәмдәл, Мүлмә, Алат, Семиозерка, Суыксу, Ташлы Кавал, Усад, Чыпчык, Чернышевка, Шәпше, Ямаширмә авыл җирлекләре вәкиллекле органнарының Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирлекләренең башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында типовой формага туры китереп кушымта нигезендә килешүләр төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакындагы карары проектын эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар

чыгарырга хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы Советының
2025 елның 08 сентябрендәге
548 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
____________ авыл җирлеге башкарма комитетының
җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетына тапшыру турында килешү

_____________ «___»__________, 2025 ел

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы ______________________авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып эш итүче Башкарма комитет җитәкчесе _______________________________________йөзендә, алга таба «Авыл җирлеге башкарма комитеты» дип аталачак, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы __________________ авыл җирлеге башкарма комитеты, бер яктан, һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып эш итүче Башкарма комитет җитәкчесе Хәкимуллин Рамил Фатыйхович йөзендә, алга таба «Район Башкарма комитеты» дип аталачак, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, икенче яктан, бергә «яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр :

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү җирлек башкарма комитетының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен Район Башкарма комитетына тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлек башкарма комитеты Район Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыра:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

1.3. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында мәгълүмат алмашырга йөкләмә алалар.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Район Башкарма комитеты әлеге Килешүнең 1 бүлеге нигезендә аңа җирлек башкарма комитеты тапшырган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.2. Район Башкарма комитеты Нигезләмә нигезендә әлеге Килешү нигезендә тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашырачак вазыйфаи затны яисә структур бүлекчәне билгели.

2.3. Район Башкарма комитеты, җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеген күрсәтү кысаларында эшләр башкару өчен, физик яисә юридик затлар белән контракт (шартнамә) төзи.

2.4. Әлеге Килешү буенча тапшырылган вәкаләтләр кысаларында эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлешендә Район Башкарма комитеты җирлек башкарма комитетына хисап тота.

### 3. Бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибе

3.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Яклар, бюджет турында ел саен раслана торган карарлар нигезендә, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен ел саен билгели *(әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымталар нигезендә)*.

3.3. Әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы, аның гамәлдә булуын туктату нигезләре һәм тәртибе

4.1. Әлеге Килешү рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.2 Әлеге Килешү 202_ елның "____" ___________ кадәр гамәлдә була.

4.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

якларның килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, үз бурычларын якларның берсе үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта йә Килешүнең алга таба гамәлдә булуы мөмкин булмавына китергән гамәлдәге законнар үзгәрү.

4.4. Әлеге Килешүне өзү турындагы хәбәрнамә, аның гамәле тәмамлану фаразланган датага кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә икенче якка җибәрелә.

4.5. Әлеге Килешү буенча тапшырыла торган бер вәкаләтләрне туктату башка вәкаләтләрне туктатуга китерми.

4.6. Әгәр әлеге Килешүнең 4.2 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң яклар Килешүне өзү ниятен утыз көн дәвамында белдермәсә, ул киләсе календарь ел тәмамланганчы озайтылган дип санала.

### 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы булалар.

5.2. Районның Башкарма комитеты тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә гамәлгә ашырмау фактын билгеләү әлеге килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора. Килешүне өзү, документаль рәвештә расланган факттагы чыгымнарны исәпкә алмаганда, өзү турында Килешүгә кул куелганнан яисә аны өзү турында язма хәбәрнамә алынганнан соң 30 көн эчендә санап үтелгән бюджетара трансфертларны кире кайтаруга, шулай ук хисап елында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан бүлеп бирелә торган бюджетара трансфертлар суммасыннан 0,01% күләмендә неустойка түләүгә китерә.

5.3. Район Башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә башкару өчен җаваплы.

5.4. Әлеге Килешүдән килеп чыга торган Район Башкарма комитеты тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанслау буенча йөкләмәләрне җирлек башкарма комитеты үтәмәгән очракта, Район Башкарма комитеты әлеге Килешүне өзүне, шулай ук китерелгән зыянны каплауны таләп итәргә хокуклы.

## 6. Башка мәсьәләләр

6.1. Якларның үзара ризалыгы яисә гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә әлеге Килешүгә язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яисә) өстәмәләр кертелергә мөмкин, алар әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3. Әлеге Килешү тигез юридик көчкә ия 2 (ике) нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы _________________ __ авыл җирлеге башкарма комитеты
Адресы: Татарстан Республикасы, Биектау районы, ________________
_____________________________________
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы __________________ _________ авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе
_____________________________________

________________
(имза)

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

Адресы: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл ст. пос, Кооператив ур., 5й.
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хәкимуллин Рамил Фатыйхович

________________
(имза)